СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.3, с. Никифорово,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Карл Маркс ур., 3 нче йорт, Никифорово авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail:.NikiforMam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар
от 22 ноябрь 2021 ел №1-12

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, « Татарстан Республикасының аерым закон актларына аерым категориядәге вазыйфаи затларның коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 07 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (18.11.2016 №2-15, 15.05.2017 №1-21, 28.07.2017 №3-22, 14.11.2017 №2-26, 05.06.2018 №2-33, 13.08.2018 №2-35, 20.11.2018 №3-38, 14.12.2018 №2-39, 21.03.2019 №1-41, 18.09.2019 №3-46, 19.02.2020 № 1-51, 17.11.2020 № 3-2, 10.07.2021 № 1-9, 08.10.2021 № 2-11 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә хезмәт шартнамәсе төзелгәнче, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмә нигезендә конкурс булырга мөмкин.»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 3 нче кушымта өстәргә:

**«3 нче кушымта**

**«**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмә» хакында**.**

## I.Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясенең (алга таба - конкурс комиссиясе) составы, аның эш тәртибе һәм сроклары, шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының (алга таба - Район) җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

1.2. Конкурс «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - Федераль закон) 17 статьясы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 статьясы нигезендә үткәрелә.

Конкурс муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс муниципаль хезмәтнең вакантлы (муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан биләнмәгән) вазыйфасы булганда, районның җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән игълан ителә.

1.4. Вакантлы вазыйфаны биләп торуга Конкурс әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә Конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

1.5. Вакантлы вазыйфаны биләп торуга Конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

1) сайланулы муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә;

2) вакытлы хезмәт шартнамәсе төзегәндә;

3) муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына билгеләгәндә, биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча аның вазыйфаи бурычларын үтәве, биләгән вазыйфасын кыскарту, җирле үзидарә органын үзгәртеп оештыру, бетерү яисә аның структурасын үзгәртү мөмкин булмаган очракта;

4) муниципаль хезмәтнең әйдәүче, өлкән, кече вазыйфалары төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләнгәндә;

5) конкурс нигезендә төзелгән кадрлар резервында торучы

муниципаль хезмәткәрне (гражданны) муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләгәндә;

6) вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле муниципаль хезмәтнең аерым вазыйфаларына билгеләнгәндә.

1.6. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарының муниципаль хезмәткә аларның сәләте һәм һөнәри әзерлеге нигезендә бертигез дәрәҗәдә керү мөмкинлеген, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукларын тәэмин итү;

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен иң туры килә торган кандидатларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саныннан сайлап алу.

1.7. Конкурсларны уздырганда хәл ителә торган бурычлар:

конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәгәндә барлык кандидатлар өчен тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмиятле критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурста катнашучылар арасында конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары таләпләренә туры килүче затларны билгеләү.

1.8. Кандидат Россия Федерациясе законнары нигезендә конкурс комиссиясе карарына шикаять белдерергә хокуклы.

1.9. Муниципаль хезмәтнең конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылар документлары һәм конкурста катнашкан кандидатлар конкурс тәмамланган көннән алып өч ел дәвамында аларга язма гариза буенча кайтарылырга мөмкин. Бу вакыт узганчы документлар архивта саклана, шуннан соң юк ителергә тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң бетерелергә тиеш.

1.10. конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

**2. Конкурс комиссиясен төзү һәм аның эш тәртибе**

Конкурслар үткәрү өчен Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә.

2.1. Конкурс комиссиясе комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясенең гомуми составы 5 кешедән дә ким була алмый.

2.2. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә.

Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.
Конкурс комиссиясе секретаре комиссия эшен тәэмин итә (гаризалар кабул итү, эшләр формалаштыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү һ.б.).
2.3. конкурс комиссиясе составына муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән муниципаль хезмәт һәм кадрлар, юридик (хокукый) бүлекчәләр), тиешле өлкәләрдә һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә белгеч булган бәйсез экспертлар (фәнни оешмалар, мәгариф учреждениеләре, җәмәгать оешмалары вәкилләре) керә.
Бәйсез экспертлар килешү буенча конкурс комиссиясе составына кертелә. Бәйсез экспертлар булып чыгыш ясаучы комиссия әгъзалары саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил итәргә тиеш.
2.4. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы, вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле рәвештә, дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.
2.5. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе кабул иткән карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килү мөмкинлеген төшереп калдырырлык итеп формалаштырыла.
2.6. конкурс комиссиясе утырышы муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат булганда уздырыла һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче әгъзалар катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.
2.7. Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста җиңүчене индивидуаль әңгәмә уздырмыйча гына билгеләү турында карар кабул итү рөхсәт ителми.
Комиссия әгъзасы яисә кандидат тәкъдиме белән Конкурс комиссиясе утырышны видеоконференция форматында уздыру турында карар кабул итәргә мөмкин, мондый карарны кабул итү өчен сәбәп (нигезләү) булырга тиеш.
2.8. Конкурс комиссиясе карар кабул иткәндә кандидат чыгып тора.
2.9. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары утырышта катнашкан әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.
2.10. Конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе алып барыла, аны утырышта катнашкан комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары имзалый.
2.11. Эш бирүченең конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына конкурста җиңүчене билгеләү турында күрсәтмәсе чыгарыла һәм конкурста җиңүче белән хезмәт килешүе төзелә.
2.12 Конкурста катнашкан кандидатларга конкурс нәтиҗәләре турында язма

рәвештә конкурс тәмамланган көннән алып бер ай эчендә хәбәр ителә.

## 3.Конкурста катнашучылар

3.1. конкурста катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнары ия.

3.2 Конкурста катнашуга муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларга карата таләпләргә туры килә торган һәм Нигезләмәнең 3.45 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган срокта тапшырган гражданнар кертелә.

3.3. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәгән, шулай ук Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр булган гражданин (муниципаль хезмәткәр) конкурска кертелми.

3.4. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга кандидатларга карата таләпләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.5 конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә тапшыра:

- әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча шәхси гариза;

- Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкетаны фотография белән;

- паспорт күчермәсе яки аны алмаштыручы документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

кирәкле һөнәри белем, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар:

- хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадр хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданның хезмәт (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар (хезмәт (хезмәт) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);

- мәгариф һәм квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданин теләге буенча өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки тапшыруны раслаучы документлар күчермәләре, гыйльми дәрәҗә бирү турында документлар, хезмәт (эш)урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган гыйльми исемнәр күчермәләре;

- гражданин хезмәтенә керүгә яки аны узуга комачаулаучы авыру булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы

белән расланган исәпкә алу формасы 001 - ГС/у);

- гамәлдәге законнарда каралган башка документлар.

3.6. Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче һәм конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр конкурс комиссиясе рәисе исеменә үзе кул куйган һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән органның кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган гаризаны, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча тутырылган анкета, фотография бирә.

3.7. Гражданның (муниципаль хезмәткәрнең) ризалыгы белән, граждан (муниципаль хезмәткәр) дәгъвалаган муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса, гражданның (муниципаль хезмәткәрнең) ризалыгы белән аның дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләргә рөхсәт алуын рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Граждан тарафыннан җирле үзидарә органы җитәкчесе исеменә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерүгә җибәрелә.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.5 һәм 3.6 пунктларында күрсәтелгән документлар, "Россия Федерациясе дәүләт муниципаль хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы" федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында(алга таба - Федераль мәгълүмат системасы), «Нократ» («Вятка») газетасында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru/ сайтында аларны кабул итү турында белдерү урнаштырылганнан соң 20 календарь көн эчендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Федераль мәгълүмат системасын кулланып почта яки электрон рәвештә файдалану юлы белән конкурс комиссиясенә гражданин (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан шәхсән тапшырыла.

Граждан (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яисә җитди сәбәпләрсез рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру аларны кабул итүдә баш тарту өчен нигез булып тора.

Документларны вакытында тапшырмаганда, аларны тулы күләмдә тапшырмаганда яисә конкурс комиссиясе рәисе карары белән аларны кабул итү сроклары күчерелергә мөмкин.

## 4. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1.Конкурслар үткәрүгә әзерлек кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү ысулларын (алга таба - бәяләү ысулларын) сайлап алуны һәм, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләре нигезләмәләрен конкурс игълан итү планлаштырылган вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфаларына карата актуальләштерүне күздә тота.

Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләре

нигезләмәләрен актуальләштерү, бәяләү ысулларын сайлау һәм аларга туры килә торган конкурс биремнәрен булдыру, җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте белән килештереп, җирле үзидарә органының кызыксынучы бүлекчәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс биремнәрен бәяләү һәм формалаштыру ысулларын куллану турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларына карата муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләрендә конкрет белгечлеккә (әзерлек юнәлешенә) карата квалификация таләпләре билгеләнергә мөмкин.

4.2.Кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның конкурс процедуралары барышында квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү өчен федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән бәяләү ысуллары, индивидуаль әңгәмәне дә кертеп, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тестлар кулланылырга мөмкин.

4.3. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4. Җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте беренче этапта түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс уздыру турында мәгълүматны Мамадыш муниципаль районының һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында әзерләү һәм урнаштыру, аңа түбәндәгеләр керә: муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы исеме, әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, муниципаль хезмәтне узу шартлары, муниципаль хезмәтне узу шартлары, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатлар тарафыннан бирелә торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документлар тәмамланганчыга кадәр кабул ителә торган вакыт, конкурсны уздыру датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясен бәяләү ысуллары, нигезләмәләре турындагы белешмәләр, башка мәгълүмати материаллар;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерү;

гражданның (муниципаль хезмәткәрнең)

квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү (һөнәри белем дәрәҗәсе, муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәр һәм күнекмәләр).

4.5.Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның муниципаль хезмәткә керүенә комачаулаучы фактлар турында билгеле булганда, аңа җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан язма рәвештә конкурста катнаштырмау сәбәпләре турында хәбәр ителә.

4.6. Россия Федерациясе законнары нигезендә вакантлы вазыйфаны биләп торуга конкурста катнашуга кертелмәгән дәгъва кылучы әлеге карарга

шикаять бирергә хокуклы.

4.7. Конкурсның беренче этабын тәмамлау шарты булып муниципаль хезмәтнең билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган бер вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат булу тора, бу кандидатларны алга таба сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаган яисә квалификация таләпләрен канәгатьләндерә торган бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер булган кандидатка таләп ителә торган кандидатлар булмау сәбәпле конкурс узмаган дип танылуы турында язма рәвештә хәбәр җибәрелә.

4.8. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, җирле үзидарә органы җитәкчесе конкурсның икенче этабын уздыру көнен (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланган көннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча), вакытын һәм урынын билгеләү турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән мәгълүматларга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын үткәрү срогын җирле үзидарә органы җитәкчесе билгели.

Җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте конкурсның икенче этабы башланганчы 15 календарь көннән дә соңга калмыйча Мамадыш муниципаль районының һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларына аны уздыру датасы, урыны һәм вакыты турындагы мәгълүматны, конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язма рәвештә тиешле хәбәрләр җибәрә.

Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү;

конкурс комиссиясе тарафыннан муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына конкурста җиңүчене билгеләү турында карар кабул итү;

Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында конкурс нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

конкурс нәтиҗәләрен Мамадыш муниципаль районы сайтларында бастырып чыгару.

4.12. Конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларның белеме, Муниципаль яки дәүләт хезмәтен узу, башка хезмәт эшчәнлеген тормышка ашыру турындагы документлар нигезендә, шулай ук тест, шәхси әңгәмәне үз эченә ала торган бәяләү методларын кулланып, конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә бәяли.

4.12.4.Тест ярдәмендә Россия Федерациясе дәүләт теле (рус теле) муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә, Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы нигезләрен, муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарын белүгә һәм коррупциягә каршы тору, мәгълүмати-коммуникация технологияләре өлкәсендә белем һәм күнекмәләр, шулай ук һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә белем һәм күнекмәләр белән белү дәрәҗәсен бәяләү гамәлгә ашырыла.

4.12.5. Кандидатлар белән индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан уздырыла.

Шәхси әңгәмә кысаларында кандидатның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүгә юнәлдерелгән сораулар бирелә.

Бу максатларда муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын исәпкә алып, муниципаль хезмәтнең һәр вакантлы вазыйфасы буенча сораулар исемлеге төзелә. Сораулар исемлеге комиссия утырышына конкурс уздырыла торган муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә структур бүлекчә җитәкчесе әзерләнә.

Кандидат белән индивидуаль әңгәмә тәмамлангач, конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы кандидатны бәяләү нәтиҗәсен әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә төзелә торган конкурс бюллетененә кертә.

Шәхси әңгәмә узу нәтиҗәләре буенча кандидат 0 дән 10 га кадәр балл алырга мөмкин.

4.13. Кандидатның йомгаклау баллы кандидатка индивидуаль әңгәмә һәм тест йомгаклары буенча кандидат җыйган баллар нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган уртача арифметик балл суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгаклау балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе секретаре аларның йомгаклау балларын кимеү тәртибендә кандидатлар рейтингын формалаштыра.

4.14. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасы буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаган булса, конкурс комиссиясе конкурста җиңүче билгеләнмәде дигән карар кабул итә.

4.15. Конкурс нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр ул тәмамланганнан соң җиде көн эчендә кандидатларга язма рәвештә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук срокта Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында урнаштырыла.

Вакантлы вазыйфаны
билэп торуга конкурс үткәрү
турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районының
җирле үзидарә органнарында муниципаль
хезмәтнең вакантлы вазыйфасын
биләүгә конкурс комиссиясенә
_______________________________
кемнән_______________________________
яшәү урыны_______________________________
паспорт_______________________
(телефон номеры, электрон почта)

Гариза

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының ________________________________________ муниципаль хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга минем кандидатурамны каравыгызны сорыйм.

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында " гы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү турындагы Нигезләмә, шул исәптән вакантлы вазыйфаны биләү өчен куела торган квалификация таләпләре белән таныштым.

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә 2006 елның 27 июлендәге №152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә "Шәхси мәгълүматлар турында" риза. Бәяләү методлары, датасы һәм урыны, конкурсны уздыру тәртибе һәм нәтиҗәләре турында хәбәр итеп, күрсәтелгән кәрәзле телефон номерына e-mail яки СМС-хәбәр аша риза.**

**Гаризага теркәп куям:**

**(беркетелгән документларны санап узарга)**

Дата                                                            имза

Вакантлы вазыйфаны
билəп торуга конкурс үткəрү
турында Нигезлəмəгə
2 нче кушымта

**КОНКУРС БЮЛЛЕТЕНЕ**

20____ елның «___» ____________

______________________________________________________________

_

биләү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфаның тулысынча аталышы

______________________________________________________________

_

яки кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган

______________________________________________________________

_

вазыйфалар төркеме атамасы

1. Шәхси әңгәмә уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатларга бирелә торган баллар (максималь балл - 10 балл).

| кандидатның ФИО | Балл | Куелган баллга кыскача дәлилләмә(зарурлык булганда) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

2. конкурс үткәрелә торган вазыйфаның атамасы
Шәхси әңгәмә уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатларга бирелә торган баллар (максималь балл - 10 балл).

| кандидатның ФИО | Балл | Куелган баллга кыскача дәлилләмә(зарурлык булганда) |
|---|---|---|
| | | |

Конкурс комиссиясе әгъзасының
фамилиясе, исеме, атасының исеме
Имза

2. 7 бүлекнең 7.1. пунктында:
2.1. 7 пунктчаны түбәндәге редакция дә бәян итәргә
Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса,

чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) яисә яшәүгә рөхсәте яки гражданның чит
дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган бүтән документы
булса;

3. 2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплы итеп Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге башлыгы С.Н. Степановны билгеләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Никифорово авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /С.Н.Степанов/